КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 август г.Казань № 661

Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен раслау турында

«Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 ел, 16 март, ТРЗ-19 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен 1 елга 1 кешегә түбәндәге күләмендә расларга:

2019 елга – 15,29 сум;

2020 елга – 15,87 сум;

2021 елга – 16,50 сум.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә

чыгымнар кыйммәтен раслау турында» 2017 ел, 30 август, 621 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин